ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш), № 74 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «керемнәр, шулай ук» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^9$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредитлары һәм» сүзләрен өстәргә, «шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагын инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджет кредитлары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^9$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредитлары» сүзләрен өстәргә;

2) 29 статьяның 3 пунктында «бурыч йөкләмәләрен түләү,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^3$ статьясындагы 1 пунктының

алтынчы абзацы һәм $93^{9}$ статьясындагы 2 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган бюджет кредитлары бирү тәртипләрендә каралган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү,» сүзләрен өстәргә, «тулыландыру» сүзеннән соң «(Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{6}$ статьясында каралган бердәм бюджет счетындагы калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларына карата)» сүзләрен өстәргә;

3) $29^{3}$ статьяның 5 пунктында «финанс белән тәэмин итүгә бюджет кредитлары» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитлары» сүзләрен өстәргә;

4) 31 статьяның $4^{1}$ пунктында:

а) беренче абзацта «бюджет кредитлары» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитлары» сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта «бюджет кредитлары» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитлары» сүзләрен өстәргә;

5) 77 статьяның 3 пунктындагы сигезенче абзацында «бюджет кредиты» сүзләреннән соң «, казначылык инфраструктура кредиты» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 28 февраль
№ 6-ТРЗ